**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ________________ ПР-230 24.10.2024 КАРАР № ________

Иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 16:04:120501:198 кадастр номерлы, 2972 кв.м мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча түбәндәге адрес буенча урнашкан:Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Иске Байсар авыл җирлеге, Иске Байсар авылы - «АЗС» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Иске Байсар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан зонада (Ит-2) җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларын билгеләргә.

2. Иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

1) Кадыйров Рәмис Мөхәммәт улы
2) Шәехова Сирина Фәнис кызы
3) Зәйнетдинов Булат Рифат улы
4) Мансурова Лилия Нажар кызы

3. Җәмәгать фикер алышуларын (гавами тыңлауларны) оештыручы Байсар авыл башкарма комитетына җирле үзидарә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә җәмәгать фикер алышуларын (гавами тыңлауларны) оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар) үткәрү 2024 елның 28 октябренә кадәр тәмамланырга тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, https://aktanysh.tatarstan.ru/.бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Р.Т.Демидовка йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов